**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДИМТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

№11 Димтамак авылы 17 сентябрь 2019 ел

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенына әзерлек һәм аны уздыру тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясын, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясын һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Димтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14 статьясын гамәлгә ашыру максатларында, Димтамак авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Кушымта нигезендә "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге торак пунктларында гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында» Нигезләмәне расларга.
2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.
3. Аның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Димтамак авыл җирлеге Башлыгы И.Ә.Сәләмов

Кушымта
Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге
Советының 2019 елның 17 сентябреннән булган 11 санлы карарына

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенына әзерлек һәм аны уздыру тәртибе турында Нигезләмә**

ӘлегеТатарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге Уставының 14 статьясы нигезендә эшләнде.

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Халык җыены гомуми, тигез һәм турыдан-туры ихтыяр белдерү нигезендә үткәрелә.

1.2. Гражданнар җыенында торак пунктта яшәүчеләр, даими яки күпчелек вакытта аның территориясендә яшәүчеләр, яшәү урыны буенча әлеге торак пунктта теркәлгән һәм сайлау хокукына ия кешеләр катнаша ала.

1.3. Гражданнар җыенында катнашу ирекле.

1.4. Һәрбер граждан җыенда шәхсән үзе катнаша һәм һәрбер граждан бер тавышка ия.

1.5. Гражданнар җыены халык тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне турыдан-туры хәл итү максатыннан үткәрелә.

Гражданнар җыены вәкаләтләре

1.6. Гражданнар җыены түбәндәге мәсьәләләр буенча үткәрелергә мөмкин:

торак пунктта җирлек чикләрен үзгәртү соравы буенча, әгәр нинди дә булса торак пункт җирлек составына керсә һәм аны башка җирлек (муниципаль район) территориясенә кертү мәсьәләсе каралганда;

муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре күрсәтелгән җирлекнең чикләрен үзгәртү, үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча гражданнар җыены белән гамәлгә ашырыла торган җирлектә;

сайлау хокукына ия булган җирлектә яшәүчеләр саны 100 дән артык кеше булса, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органын төзү, аның саны һәм вәкаләтләр вакыты турында мәсьәлә буенча;

муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены белән гамәлгә ашырыла торган җирлектә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча;

җирлек составына керүче торак пунктта, шәһәр эчендәге район, федераль әһәмияттәге шәһәр эчендәге территориядә, шәһәр округында яисә муниципаль район чикләрендә урнашкан, авылара территориядә урнашкан торак пунктта әлеге торак пункт территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча;

җирлекара территориядә урнашкан торак пунктта, җирле үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру белән бәйле мәсьәләләр буенча халык инициативасын тәкъдим итү максатларында;

авыл җирлегенең тыгызлыгы түбән булган территориясендә яки халык саны 100 кешедән артмаган, үтүе авыр булган торак пунктта, җирлекне бетерү соравы буенча;

авыл торак пунктында авыл җирлеге старостасы кандидатурасын тәкъдим итү, шулай ук авыл җирлеге старостасы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату соравы буенча;

авыл торак пунктында гражданнар җыены шулай ук муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс үткәргәндә конкурс комиссиясе составына кандидатуралар тәкъдим итү максатларында үткәрелергә мөмкин.

Гражданнар җыенын матди һәм оештыру ягыннан тәэмин итү

1.7. Гражданнар җыенын уздыру муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан тәэмин ителә.

1.8. Җыенга әзерлек һәм аны үткәрү белән бәйле чыгымнар муниципаль берәмлек бюджеты хисабына башкарыла.

## 2. Гражданнар җыенын чакыру тәртибе

Гражданнар җыенын үткәрү инициативасы

2.1. Торак пунктта гражданнар җыенын үткәрү инициативасы түбәндәгеләрнеке була:

- муниципаль берәмлек башлыгыныкы;
- сайлау хокукына ия булган, гражданнар җыенында катнашырга хокуклы торак пунктта яшәүче, 10 кешедән дә ким булмаган (ягъни Россия Федерациясенең эшкә сәләтле гражданнары), даими яки

күбесенчә торак пункт территориясендә яшәүче, яшәү урыны буенча әлеге торак пунктта теркәлгән, 18 яшькә җиткән ггражданнар, шулай ук Россия Федерациясенең халыкара килешүләре һәм федераль законнар нигезендә җирле үзидарәне гамәлгә ашырганда хокукларга ия булган, торак пункт территориясендә даими яисә нигездә яшәүче һәм җирле үзидарәне гамәлгә ашырганда хокукка ия булган чит ил гражданнары.

2.2. Торак пунктта яшәүчеләрнең инициативасы имзалар кәгазе (1 нче кушымта) яисә инициатив төркем җыелышының җыен үткәрү инициативасын күрсәтү турында карар кабул ителгән беркетмәсе рәвешендә рәсмиләштерелергә тиеш, аларда түбәндәгеләр күрсәтелгән булырга тиеш:

гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләр;

гражданнар җыенын үткәрүнең тәкъдим ителгән вакыты;
гражданнар җыенын чакыру турындагы инициативаны хуплаучы һәр гражданинның паспорт сериясе һәм номеры, яшәү урыны, аның имзасы һәм имзасын кертү датасы.

2.3. Җыенны үткәрү инициативасын хуплау өчен җыелырга тиешле имзалар саны сайлау хокукына ия булган, даими яки күпчелек вакытта яшәүче, яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар санының 5 процентын тәшкил итә, ләкин имзалар саны 25тән дә ким була алмый.

2.4. Имза куелган кәгазьләр имзалар җыючы зат тарафыннан раслана, раслау датасын, фамилиясен, атасының исемен, туган елын, паспорт номерын һәм сериясен, яшәү урынын күрсәтеп, муниципаль берәмлек башлыгына җибәрелә.

Гражданнар җыенын үткәрү турында карар кабул итү тәртибе

2.5. Инициатив төркем тарафыннан чакырыла торган гражданнар җыены муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән (*2 нче кушымта*), ә муниципаль берәмлек башлыгы инициативасы белән – муниципаль берәмлек башлыгы карары белән *(3 нче кушымта)* барлык кирәкле документлар кергән көннән 30 көн эчендә билгеләнә.

2.6. Муниципаль берәмлек башлыгы яисә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы аның максатка ярашлы булмавын сәбәп итеп, гражданнар җыенын үткәрүдән баш тартырга хокуклы түгел.

2.7. Гражданнар җыенына чыгарылган мәсьәлә Россия Федерациясе законнарына һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килмәскә тиеш. Халык җыенына куелган сорау аны күп төрле итеп аңлату мөмкинлегеннән чыгып куелырга тиеш түгел, ягъни аңа бер мәгънәле генә җавап бирелергә тиеш.

2.8. Гражданнар җыенын билгеләү, аны күчерү турындагы карарны рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) тәртибе муниципаль берәмлек уставы белән билгеләнә һәм муниципаль хокукый актларны

бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен муниципаль берәмлек уставында каралган тәртиптә басылып чыга (халыкка җиткерелә).

Муниципаль берәмлек башлыгы карарында яисә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карарында гражданнар җыенын уздыру турында түбәндәгеләр күрсәтелә: гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәлә; гражданнар җыенын уздыру вакыты һәм урыны турында мәгълүмат; җыенны оештыручы-муниципаль берәмлек органының структур бүлекчәсе турында мәгълүмат.

2.9. Гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү өчен җаваплы муниципаль берәмлек органының структур бүлекчәсе (башкарма-боеру органы) муниципаль берәмлек башлыгы карары яки муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары нигезендә гражданнар җыенын үткәрү турында сайлау хокукына ия булган торак пунктта яшәүчеләр исемлеген төзи; гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерли; муниципаль берәмлек халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итә. *(№4 кушымта).*

Муниципаль берәмлекнең башкарма-боеру органы гражданнар җыенын үткәрү өчен бина бирергә тиеш.

2.9.1. Торак пунктта яшәүчеләргә халык җыенын үткәрү вакыты һәм урыны турында алдан ук хәбәр ителә. Гражданнар җыенын билгеләү турындагы карар, гражданнар җыенын үткәрү вакыты һәм урыны гражданнар җыенына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча алдан бастырылып чыгарылырга (халыкка игълан ителергә) тиеш.

2.9.2. Гражданнар җыенына 5 көннән дә соңга калмыйча, әлеге нигезләмәнең 2.9 пунктында күрсәтелгән муниципаль берәмлек органының структур бүлекчәсендә гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышырга, шулай ук аларның күчермәләрен алырга хокуклы.

2.10. Гражданнар җыены турындагы Нигезләмәгә ярашлы, халык җыенын үткәрү датасы соңрак вакытка күчерелергә мөмкин. Халык җыенын уздыру датасын күчерү турында карар, билгеләнгән датага кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.

3. Гражданнар җыенын үткәрү тәртибе

3.1. Җыенга килгән гражданнар торак пунктта яшәүчеләр исемлегенә кертелгән һәм сайлау хокукына ия булган затларны теркәү өчен муниципаль берәмлек башлыгы вәкаләт биргән зат тарафыннан теркәлә. Исемлектә гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы, яшәү урыны, паспорт сериясе һәм номеры күрсәтелә.

3.2. Җыенда анда катнашырга теләк белдергән башка гражданнар хәлиткеч тавыш бирү хокукыннан башка катнаша ала, җыенда тикшерелә торган сорауларны хәл итү алар эшчәнлеге белән бәйле

предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләре, матбугат һәм башка массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре дә катнашырга мөмкин.

3.3. Сайлау хокукына ия торак пунктта яшәүчеләр исемлегендә төгәлсезлекләр ачыкланган очракта, торак пунктта яшәүче кеше теркәлергә һәм әлеге муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан җыенда катнаштырылырга мөмкин.

3.4. Язмаларның төгәлсезлеген (яки аларның булмавын) раслаучы документ булып гражданның шәхесен раслаучы документ (Россия Федерациясе гражданины паспорты, хәрби билет, чит ил гражданы паспорты, Россия Федерациясендә яшәүгә рөхсәт, Россия Федерациясендә вакытлыча яшәүгә рөхсәт һәм башкалар булырга мөмкин) хезмәт итәала.

3.5. Гражданнар җыены анда сайлау хокукына ия булган торак пунктта яшәүчеләрнең яртысыннан артыгы катнашканда тулы хокуклы була. Кворум булмаганда, гражданнар җыенын үткәрүнең яңа датасын билгеләү муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан башкарыла. Бу очракта халык җыены халык җыенын үткәрү билгеләнгән көннән соң ун көннән дә иртә үткәрелергә тиеш түгел.

3.6. Гражданнар җыенында тавыш бирү ачык яисә яшерен булырга мөмкин.

Тавыш бирү формасы турындагы карар гражданнар җыены тарафыннан кабул ителә (вариант буларак: форма гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә белән билгеләнә).

3.7. Гражданнар җыенында катнашу өчен теркәлгән гражданга яшерен тавыш бирүне уздырганда тавыш бирү өчен бюллетень бирелә (5 нче кушымта).

3.8. Гражданнар җыенында муниципаль берәмлек башлыгы яисә гражданнар җыенында катнашкан теркәлгән гражданнар арасыннан ачык тавыш бирү юлы белән сайланган башка зат рәислек итә ала. Рәислек итүче кандидатурасын гражданнар җыенында катнашучылар тәкъдим итәргә хокуклы.

3.9. Гражданнар җыены сәркатипне һәм хисап комиссиясен сайлый. Хисап комиссиясе әгъзалары саны ике кешедән дә ким булырга тиеш түгел. Гражданнар җыенының көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләр рәислек итүче, муниципаль берәмлек башлыгы, гражданнар җыенында катнашу хокукына ия гражданнар тарафыннан кертелә ала. Көн тәртибенә чакырылыш инициаторлары тарафыннан кертелгән сораулар мәҗбүри рәвештә кертелә. Әлеге сораулар беренче чиратта карала. Халык җыенының көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләрне кертү турында карар, әгәр аның өчен җыенда катнашкан гражданнарның яртысыннан да ким булмаган өлеше тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.

3.10. Җыен, җыенда рәислек итүче тарафыннан ачыла. Гражданнар җыенында рәислек итүче гражданнар җыенын үткәрүне оештыра, тәртип саклый, хисап комиссиясе эшен координацияли, фикер алышына торган мәсьәләләр буенча чыгыш ясау өчен сүз бирә, тавыш бирүнең билгеләнгән тәртибен тәэмин итә.

3.11. Гражданнар җыенында секретарь тарафыннан беркетмә алып барыла, анда түбәндәгеләр күрсәтелә: җыен үткәрү датасы һәм урыны, торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына ия гражданнар саны, катнашучылар саны, көн тәртибе, чыгышларның кыскача эчтәлеге, карала торган мәсьәләләр буенча тавыш биргән гражданнар саны *(6 нчы кушымта)*.

3.12. Беркетмәгә җыенда рәислек итүче зат һәм җыен секретаре тарафыннан кул куела һәм ул муниципаль берәмлек башлыгына тапшырыла. Беркетмәгә җыенда теркәлгән катнашучылар исемлеге теркәлә.

## 4. Гражданнар җыены карарлары

4.1. Гражданнар җыены карары, әгәр аның өчен сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучыларның яртысыннан артыгы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.

4.2. Җыенда кабул ителгән карарлар муниципаль хокукый актлар булып тора, муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан имзалана һәм Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелергә тиеш *(№7, 8 кушымталар)*.

4.3. Җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары гражданнар җыенында кабул ителгән карарларның җирлек уставы белән билгеләнгән вәкаләтләрне чикләү нигезендә үтәлешен тәэмин итәләр.

4.4. Җыенда кабул ителгән карар җыенда башка карар кабул итү юлы белән юкка чыгарылырга яки үзгәртелергә мөмкин яки суд тәртибендә гамәлдә түгел дип танылырга мөмкин.

4.5. Гражданнар җыенында кабул ителгән карарлар рәсми бастырылып чыгарылырга (халыкка игълан ителергә) тиеш һәм муниципаль хокукый актларга кулган таләпләре нигезендә рәсмиләштерелә.

4.6. Әгәр торак пунктта яшәүчеләрне турыдан-туры ихтыяр белдерү юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен өстәмә рәвештә муниципаль хокукый акт кабул итү (бастырып чыгару), күрсәтелгән актны кабул итү (бастырып чыгару) компетенциясенә керә торган җирле үзидарә органы яисә җирле үзидарәнең вазыйфаи заты гражданнар җыенында кабул ителгән карар үз көченә кергән көннән соң 15 көн

эчендә тиешле муниципаль хокукый актны әзерләү һәм (яисә) кабул итү вакытын билгеләргә тиеш. Күрсәтелгән срок өч айдан да артмаска тиеш.

Гражданнар җыены карарларын үтәү

4.7. Җыенда кабул ителгән карарлар торак пункт территориясендә мәҗбүри үтәлергә тиеш һәм нинди дә булса дәүләт хакимияте органнары, аларның вазыйфаи затлары яисә җирле үзидарә органнары тарафыннан раслануга мохтаҗ түгел.

4.8. Җыенда кабул ителгән карарларны үтәмәү закон нигезендә җавап тотуга сәбәп булып тора.

Кушымта 1
Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль
районы Димтамак авыл җирлеге составына
керүче торак пунктларда гражданнар җыенын
әзерләү һәм уздыру тәртибе турында
Нигезләмәгә

ИМЗАЛАР КУЮ КӘГАЗЕ

Без, түбәндә имза куючылар, ______________________________________________________

(гражданнар җыенын уздыру сроклары)
Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге _
____ торак пунктында ________________________________________ соравы буенча гражданнар җыенын уздыру инициативасын хуплыйбыз

| №№ т/б | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Туу датасы | Яшәү урыны адресы | Паспортның яки аны алыштыручы документның сериясе, номеры | Имзаны кую датасы | Имза |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Имзалар кәгазен раслыйм _____________________________________
(имзалар җыюны башкарган затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы,
______________________________________________________________________
Яшәү урыны, паспортының яки аны алыштыручы документының сериясе һәм номеры
_____________________ (имза һәм дата)

Кушымта 2
Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль
районы Димтамак авыл җирлеге составына
керүче торак пунктларда гражданнар җыенын
әзерләү һәм уздыру тәртибе турында
Нигезләмәгә

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДЫМ-ТАМАКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Дым-Тамак, ул.Новая, д.4в, , 423955

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ДИМТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Димтамак авылы, Яна урам, 4 в йорт,
423955

Тел.:(85593) 4-52-37, факс:4-52-37, e-mail: Dtam.Utz@tatar.ru

---

# КАРАР

**_______20**г.** **№ ____**

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге ______ торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

06.10.2003 елның октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Димтамак авыл җирлеге Уставының 14 статьясы нигезендә, Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. 20**елның _____ Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге ________ торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:
“Сез Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән (үзара салымнан азат ителгән гражданнар категориясен күрсәтергә) 20__ елда ___ сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә ризамы?:
“ӘЙЕ” «ЮК»

2. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтына урнаштыру юлы белән _ _ _ _ көн эчендә игълан итәргә.

3. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Димтамак авыл җирлеге башлыгы ФИА_________

Кушымта 3
Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль
районы Димтамак авыл җирлеге составына
керүче торак пунктларда гражданнар җыенын
әзерләү һәм уздыру тәртибе турында
Нигезләмәгә

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДЫМ-ТАМАКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Дым-Тамак, ул.Новая, д.4в, , 423955

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ДИМТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Димтамак авылы, Яна урам, 4 в йорт,
423955

Тел.:(85593) 4-52-37, факс:4-52-37, e-mail: Dtam.Utz@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Димтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башлыгы карары 20 ___ елның ___ N__ _**

"Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында"

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге Уставының 14 статьясы, Ютазы муниципаль районының «Димтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРӘ:

1. 20___ елның _____ нә Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегенең _____ торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыруны билгеләргә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешенең ______ категорияләреннән тыш, 20_ _ елда ___ сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы ?

«ӘЙЕ» “ЮК".

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтына урнаштыру юлы белән _ _ _ _ көн эчендә игълан итәргә.

3. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

“Димтамак авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгы ФИА

Кушымта 4
Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль
районы Димтамак авыл җирлеге составына
керүче торак пунктларда гражданнар җыенын
әзерләү һәм уздыру тәртибе турында
Нигезләмәгә

_________________________________ ________________________________
(муниципаль район исеме) (җирлек исеме)
_____________(торак пункт исеме)
____________________ нда яшәүче сайлау хокукына ия булган яшәүчеләр

ИСЕМЛЕГЕ

«___» __________________ 20___ ел

| №№ т/б | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Туган елы (18 яше тулган зат – туган ае, көне) | Яшәү урыны адресы | Паспорт сериясе, номеры | Имза |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

Гражданнар җыенында рәислек итүче _________ ______________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)
Гражданнар җыены сәркатибе _________ ______________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)

Кушымта 5
Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль
районы Димтамак авыл җирлеге составына
керүче торак пунктларда гражданнар җыенын
әзерләү һәм уздыру тәртибе турында
Нигезләмәгә

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге составына керүче ______________торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча яшерен тавыш бирү **БЮЛЛЕТЕНЕ**

| | | |
|---|---|---|
| Яшерен тавыш бирүгә куелган сорауның эчтәлеге | «Әйе» | ☐ |
| | «Юк» | ☐ |
| | «Тыелып калам» | ☐ |

Кушымта 6
Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль
районы Димтамак авыл җирлеге составына
керүче торак пунктларда гражданнар җыенын
әзерләү һәм уздыру тәртибе турында
Нигезләмәгә

## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ БЕРКЕТМӘСЕ

________________________________________

«___» ____________ 20__ ел №_____

____________________________________
(торак пунктның исеме )

Катнаштылар ____________________________________________ кеше
(торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына ия гражданнар саны, катнашучылар саны)

Гражданнар җыенында рәислек итүче ____________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Гражданнар җыены сәркатибе ____________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

**КӨН ТӘРТИБЕ:**

1.

2.

**Беренче сорау буенча тыңладык:**
__________________________________________
(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки доклад тексты теркәлә)

**Чыгыш ясадылар:** 1. ________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки чыгыш тексты (теркәлә) һ.б.ш. (чыгыш ясаган гражданнар саны буенча)…

**КАРАР ИТЕЛДЕ:** (карарның эчтәлеге)

Тавыш бирү нәтиҗәләре: «Әйе» - ____ кеше
«Юк» - ____ кеше
«Тыелып калган» - ____ кеше

Карар ________________________
кабул ителде (кабул ителмәде)

**Икенче сорау буенча тыңланды:**
__________________________________________
(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

(чыгышның кыскача язмасы яки доклад тексты теркәлә)

**Чыгыш ясадылар:** 1. ________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

(чыгышның кыскача язмасы яки чыгыш тексты (теркәлә) һ.б.ш. (чыгыш ясаган гражданнар саны буенча)…

**КАРАР ИТЕЛДЕ:** (карарның эчтәлеге)

Тавыш бирү нәтиҗәләре : «Әйе» - ____ кеше

«Юк» - ____ кеше

«Тыелып калган» - ____ кеше

Карар ________________________

Кабул ителде (кабул ителмәде)

Гражданнар җыенында рәислек итүче ________ ________________

(имза) (имзаның расшифровкасы)

Гражданнар җыены секретаре ________ ________________

(имза) (имзаның расшифровкасы)

Кушымта 7
Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль
районы Димтамак авыл җирлеге составына
керүче торак пунктларда гражданнар җыенын
әзерләү һәм уздыру тәртибе турында
Нигезләмәгә

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге составына кергән _________ торак пунктларындагы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында КАРАР

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде. “Сез Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге ______торак пунктында 20* елда Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге составына керүче торак пунктта яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны конкрет юнәлешләргә җибәрү белән килешәсезме

1)...; 2)....

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмәгә ярашлы:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә ____ халык җыенында катнашучы кертелде.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан ___ граждан тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен халык җыенда катнашкан ____ граждан тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены карар итте:

Ютазы муниципаль районы составына керүче Димтамак авыл җирлегендә ________ торак пунктында узган халык җыенын – узган, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

Түбәндәге сорау буенча карар кабул телгән дип танырга: «Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге ______ торак пунктында 20** * елда Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге составына керүче торак пунктта яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, .... башка (ташламалардан файдаланучылар категориясе) һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?: 1)...; 2)...

__________ муниципаль районы _________ җирлегенең һәм гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә (гражданнар җыены нәтиҗәләрен халыкка җиткерү ысулын күрсәтергә)

Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче ________________ ________________
(имза) (имза расшифровкасы)

Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет рәисе _________________ ________________
(имза) (имза расшифровкасы)

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

________________________________________________________

(Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге _________ торак пунктында
«___» ____________ 20__ ел № _____

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә,

гражданнар җыены _______________________________________________**КАРАР ИТТЕ:**
(торак пунктның исеме)

1.
2.
3.

Гражданнар җыенында рәислек итүче __________ ______________
(имза) (имза расшифровкасы) подписи)

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе _________ ______________
(имза) (имза расшифровкасы)